**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 07.06.2022** **№ 572**

**Рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, халыкның фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 4 июленә Новикова Людмила Анатольевна (1/3 өлеш), Новиков Никита Сергеевич (1/3 өлеш) һәм Габдрахманова Аделина Рөстәмовна (1/3 өлеш) гомуми өлешле милкендәге 16:16:080302:121 кадастр номерлы 1 347 квадрат метр мәйданлы җир кишәрлегенә рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча фикер алышу өчен, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау ав., Юбилей ур., 1А й., Биектау авыл җирлеге администрациясе бинасы адресы буенча 14 сәг. 00 минутка гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Әлеге карарны һәм гавами тыңлаулар үткәрү турында мәгълүматны Биектау авыл җирлеге территориясендәге махсус җиһазландырылган стендларда, Биектау авыл җирлеге территориясендә урнашкан ТР Биектау муниципаль районы карамагындагы биналарда 2022 елның 6 июненнән 2022 елның 1 июленә кадәр чорда һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә (халыкка җиткерергә).

3. Гавами тыңлауларда каралырга тиешле мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне кабул итүне язма рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты бинасында, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау станциясе т/юл.п., Кооператив ур., 5 йорт адресы буенча эш көннәрендә көн саен 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр 2022 елның 6 июненнән 2022 елның 1 июленә кадәр чорда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм

торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдинов тарафыннан һәм шулай ук 2022 елның 4 июлендә турыдан-туры гавами тыңлаулар уздырганда гамәлгә ашырырга.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә. Тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерергә.

5. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә һәм аны Биектау авыл җирлеге территориясендәге, Биектау авыл җирлеге территориясендә ТР Биектау муниципаль районы карамагындагы биналарда махсус җиһазландырылган стендларда урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы А.М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Хисамутдинов